ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

08 ноября 2019 г. № 5758

Башкарма комитетның 2018 елның 1 ноябрендәге 6510 нчы карары белән расланган «2019-2021 елларга Яр Чаллы шәһәрендә дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 16 маддәсе, шәһәр Уставының 41 маддәсе, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 нчы карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2018 елның 1 ноябрендәге 6510 нчы карары белән расланган «2019-2021 елларга Яр Чаллы шәһәрендә дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру» муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 6 бүлекнең «Таҗик, лезгин, азербайҗан, үзбәк, казах, башкорт җәмгыятьләрендә «Нәүрүз» милли бәйрәмен оештыру һәм үткәрү» юлында «Чыганакны күрсәтеп, финанслау күләме, мең сум» 2019 ел» графасындагы «30,0» цифрларын «27,5» цифрларына алмаштырырга;

- 6 бүлекнең «Яр Чаллы шәһәрендә «Нәүрүз» милли бәйрәмен оештыру һәм үткәрү» юлында «Чыганакны күрсәтеп, финанслау күләме, мең сум» 2019 ел» графасындагы «50,0» цифрларын «47,0» цифрларына алмаштырырга;

- 6 бүлекнең «Татарстан Республикасы фин-угыр халыкларының «Без бер агач тармаклары» халык иҗаты фестивален оештыру һәм үткәрү» юлында «Чыганакны күрсәтеп, финанслау күләме, мең сум» 2019 ел» графасындагы «100,0» цифрларын «99,337» цифрларына алмаштырырга;

- 6 бүлекнең «Каз өмәсе» халык-йола бәйрәме» юлында «Чыганакны күрсәтеп, финанслау күләме, мең сум» 2019 ел» графасындагы «75,0» цифрларын «85,973» цифрларына алмаштырырга;

- 6 бүлекнең «Май чабу» шәһәр бәйрәмен оештыру һәм үткәрү» юлында «Чыганакны күрсәтеп, финанслау күләме, мең сум» 2019 ел» графасындагы «75,0» цифрларын «70,190» цифрларына алмаштырырга.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы И.А. Сәгыйдуллинага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин